ГЛАВА
ЭБАЛАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2019 елның 10 нчы октябере Ябалак авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Морза Бәрлебаш авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 23 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Морза Бәрлебаш авылы, Беренче Май урамы,15А адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Морза Бәрлебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча граңданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 24 октябрендә 15 сәгать 00 минутка Морза Бәрлебаш авылы,Беренче Май урамы,32Б йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча граңданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Морза Бәрлебаш авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле

əһəмияттəге мəсьəлəлəрне хəл итүгə алынган акчаларны түбəндəге эшлəрне башкару буенча хəл итүгə юнəлдерү белəн килешəсезме?:

*а) җирлек территориясен төзеклəндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;

*б) җирлек чиклəрендə халыкны су белəн тəэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, суүткəргеч челтəрлəрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чиклəрендə җирле əһəмияттəге автомобиль юлларына карата юл эшчəнлеге:*

- җирлекнең торак пунктлары чиклəрендə автомобиль юлларын карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Əлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең мəгълүмат стендларында урнаштыру юлы белəн халыкка таратырга һəм «Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рəсми сайтында урнаштырырга.

8. Əлеге карар басылып чыккан көненнəн үз көченə керə.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзəтуллина М. Ф.